ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**28.04.2023г**

Зеленодольск
шәһәр

**КАРАР**
**№ 1283**

«Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә ярдәм чаралары турында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 27 октябрендәге 2968 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 14 ноябрендәге 1213 номерлы карары буенча, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә ярдәм чаралары турында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 27 октябрендәге 2968 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында 1-11 сыйныф укучылары булган гаилә әгъзаларына Зеленодольск муниципаль районы бюджеты хисабыннан 2022 елда һәр уку көненә 95,55 сумга, 2023 елда 101,38 сумга бушлай ике тапкыр кайнар ризык (иртәнге, төшке аш) бирү;».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 27 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В. Старостин